| ГЛАВА МАЙНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАЙНА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с.Верх.Тат.Майна** **КАРАР**

**30.10.2020** **№ 3**

**«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Алексеевск муниципаль районының Майна авыл җирлегенең Чуаш Майнасы авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Алексеевск муниципаль районының Майна авыл җирлеге Уставының 23 маддәсе нигезендә

**карар бирәм:**

1. 2020 елның 10 ноябренә 14 сәгать 00 минутта Алексеевск муниципаль районының Майна авыл җирлегенең Чуаш Майнасы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Майна авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2021 елда үзара салым кертүгә сез, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- авыл эчендәге юлларны вак ташлау һәм төзекләндерү;
- җәйге һәм кышкы чорда җирлек эчендәге юлларны карап тоту;
- ял итү зоналарын төзекләндерү;
- балалар уен мәйданчыгын сатып алу һәм урнаштыру;
- янгынга каршы гидрантлар сатып алу һәм урнаштыру;

- су башнясы өчен су насосы алу;
- контейнер мәйданчыгы төзү һәм контейнерлар сатып алу;
- терлекләр өчен коймалар (материал сатып алу);
- урамнарны яктырту.

ӘЙЕ   ЮК».

3. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Алексеевск муниципаль районының Майна авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

3. Җыен үткәрү урыны итеп түбәндәге адрес буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасын билгеләргә: Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Чуаш Майнасы ав., Мәктәп ур., 10 й.

5. Әлеге карарны Майна авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Чуаш Майнасы ав., Мәктәп ур., 10 й.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Алексеевск муниципаль районынын**
**Майна авыл җирлеге башлыгы** **Р.Н.Гафиятуллин**